**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы карары**

Зур Сукаеш авылы № 29 2018 ел "10" октябрь

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 38 номерлы "Җир салымы турында" карарына үзгәреш кертү турында. (2015 елның 18 августындагы 20 номерлы , 2017 елның 07 августындагы 9 номерлы карарлар редакциясендә)

О внесении изменения в решение Сухояшского Совета сельского поселения Азнакаевского муниципального района Республики Татарстан от 24.11.2014 №38 «О земельном налоге» (в редакции решения от 18.08.2015 № 20, от 07.08.2017 № 9)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 52 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 03 августындагы 334-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Сукаеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 38 номерлы "Җир салымы турында " карарына (2015 елның 18 августындагы 20 номерлы ,2017 елның 07 августындагы 9 номерлы карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертергә, түбәндәге эчтәлекле 6 пунктчаның 4 пунктын тулыландырып:

“6) балачактан инвалидлар, инвалид балалар. "

2. Әлеге карар рәсми матбугат басмасында басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта - "Маяк" газетасында үз көченә керә һәм физик затларның җир салымын 2015 елның 1 гыйнварыннан исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга, веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштырырга: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http//aznakayevo. tatastan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Җ.Закирова